| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>ГОРОДА БУИНСКА | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БУА<br>ШӘҺӘРЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
| --- | --- |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 24 » 10 2018 ел Буа шәһәре № 59

Социаль файдаланудагы торак фонды
торак урыннарына наем килешүе буенча
торак урыннар тәкъдим итү турында
гражданнар гаризаларын наем бирүчеләр
тарафыннан исәпкә алу тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 91.14 статьясы 5 өлеше 1 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Буа шәһәре Башкарма комитеты

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Әлеге карарга теркәлгән Социаль файдаланудагы торак фонды торак урыннарын наем килешүе буенча торак урыннар тәкъдим итү турында гражданнар гаризаларын наем бирүчеләр тарафыннан исәпкә алу тәртибен расларга.
2. Әлеге карар имза куелган көннән үз көченә керә һәм рәсми рәвештә халыкка игълан ителергә тиеш.

Буа шәһәре
Башкарма комитеты җитәкчесе А.И. Хабибрахманов

ТР Буа муниципаль районы
Буа шәһәре Башкарма комитетының
2018 елның 24 октябрендәге
59 номерлы карары белән
расланган

**Социаль файдаланудагы торак фонды торак урыннарын наем килешүе буенча торак урыннар тәкъдим итү турында гражданнар гаризаларын наем бирүчеләр тарафыннан исәпкә алу тәртибе**

1. Әлеге норматив акт белән наем бирүчеләр тарафыннан социаль файдаланудагы торак фонды торак урыннарын наем килешүе буенча торак урыннар тәкъдим итү турында гражданнар гаризаларын исәпкә алу тәртибе билгеләнә, әгәр наем бирүчеләр түбәндәгеләр булса:

а) ТР Буа муниципаль районы Буа шәһәре муниципаль берәмлеге;

б) муниципаль торак фондының торак урыннары милекчесе сыйфатында, муниципаль берәмлек исеменнән чыгарга вәкаләтле оешма;

в) шәхси торак фонды торак урыннары милекчеләре булган яки андый торак урыннарының милекчеләре тарафыннан, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Социаль билгеләнүдәге торак фонды торак урыннарын наемга алу буенча мөнәсәбәтләрне җайга салу турында» 2014 елның 5 декабрендәге 1318 номерлы карары белән билгеләнгән таләпләргә җавап биргән вәкаләтле оешма.

2. Наем бирүче социаль файдаланудагы торак фонды торак урыннарын наем килешүе буенча торак урыннар тәкъдим итүгә мохтаҗ булган гражданнар исәбенә алынган гражданнар (алга таба, шулай ук – гариза бирүче) биргән социаль файдаланудагы торак фонды торак урыннарын наем килешүе буенча торак урыннар тәкъдим итү турындагы гаризаларны (алга таба – гариза) исәпкә алуны башкара.

3. Гариза әлеге Тәртипкә 1нче кушымтада китерелгән формада бирелә.

4. Шәхсән бирелгән гаризаны исәпкә алу, аны биргәндә турыдан-туры башкарыла. Гариза почта аша җибәрелгән очракта, гариза наем бирүче гариза белән почта җибәрүен алган көнне исәпкә алына.

5. Гариза социаль файдаланудагы торак фонды торак урыннарын наем килешүе буенча торак урыннар тәкъдим итү турында гариза биргән гражданнар реестрында (әлеге Тәртипнең 2нче кушымтасы), әлеге Тәртипнең нигезләмәләрен исәпкә алып, кирә торган документларны теркәү өчен билгеләнгән тәртиптә теркәлә.

6. Гариза бирүчегә ул гариза биргән көндә әлеге Тәртипнең 3 кушымтасында китерелгән форма буенча гариза кабул итү һәм исәпкә алу турында расписка бирелә. Гариза почта аша җибәрелгән очракта, гаризаны кабул итү һәм исәпкә алу турындагы расписка наем бирүче тарафыннан почта аша гаризада күрсәтелгән адрес буенча наем бирүче гариза белән почта җибәрүен алган көннән өч эш көненнән дә соңармыйча җибәрелә.

7. Наем бирүче гаризаны исәпкә алган көннән бер ай дәвамында тикшерү үткәрергә хокуклы:

а) гаризада күрсәтелгән мәгълүматларның дөреслеген;

б) гариза бирүченең социаль файдаланудагы торак фонды торак урыннарын наем килешүе буенча торак урыннар тәкъдим итүгә мохтаҗлар исемлегенә кертелүен;

в) социаль файдаланудагы торак фонды торак урыннарының башка наем бирүчеләренә шундый ук гариза бирү булмавын, шул исәптән муниципаль берәмлек территориясендә төзелүче социаль файдаланудагы наем йортларында (башка наем бирүчеләр булганда).

8. Үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре буенча наем бирүче тикшерү тәмамланганнан соң 5 эш көне дәвамында гариза бирүчегә тикшерү нәтиҗәләре турында хәбәр җибәрә. Хәбәр гариза бирүчегә гаризада күрсәтелгән адрес буенча почта җибәрүе белән эченә салынганның исемлеге һәм тапшыру турындагы белдерү белән юнәлдереләә яки имза куйдырып шәхсән тапшырыла.

9. Әгәр тикшерү үткәрү нәтиҗәсендә наем бирүче гаризада китерелгән мәгълүматларның дөрес түгеллеген ачыкласа, наем бирүче гариза бирүчегә әлеге Тәртипнең 8 пунктында күрсәтелгән хәбәрдә бер ай дәвамында дөрес мәгълүматлар белән яңа гариза китерергә тәкъдим итә. Әгәр гариза бирүче бер ай срок эчендә яңа гариза бирмәсә яисә, әгәр тикшерү гаризаны кабул итүдән баш тарту өчен Россия Федерациясе Торак кодексының 91.14 статьясы 4 өлешендә каралган нигез булуын ачыкласа, гаризаны исәпкә алу турындагы реестрда язу наем бирүченең язмача карары нигезендә гамәлдән чыгарыла.

Социаль файдаланудагы торак фонды
торак урыннарына наем килешүе буенча
торак урыннар тәкъдим итү турында
гражданнар гаризаларын наем бирүчеләр
тарафыннан исәпкә алу тәртибенә
1нче кушымта

Гражданинның социаль файдаланудагы торак фонды торак урыннарына наем килешүе буенча торак урыннар тәкъдим итү турында гаризасы формасы

______________________________________
(кемгә)
______________________________________

______________________________________
(кемнән – фамилиясе, исеме, атасы исеме)
______________________________________
(адрес буенча яшәүче)
______________________________________

**Гариза**

Социаль файдаланудагы торак фонды торак урыннарына наем килешүе буенча торак урын тәкъдим итәргә сорыйм.

Мин «____»_________ 20____елда социаль файдаланудагы торак фонды торак урыннарына наем килешүе буенча торак урын тәкъдим итүгә мохтаҗлар исәбенә ______________________________________________________________

«_____»__________ 20____ елның №_____ карары белән кабул ителдем.

Торак урында ялгызым/гаилә белән (кирәклесенең астына сызарга) яшәргә уйлыйм. Гаилә составында_______кеше:

| № п/п | Фамилия, исем, атасы исеме | Туганлык дәрәҗәсе | Туган көн, ай, ел |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |

Мин наем бирүче тарафыннан үземнең персональ мәгълүматларны эшкәртүгә, шул исәптән әлеге гаризаны исәпкә алу өчен кирәкле барлык гамәлләрне башкару максатында персональ мәгълүматларны җыю, системалаштыру, туплау, саклау, аныклау (яңарту, үзгәртү), файдалану, тарату (шул исәптән тапшыру), шәхси үзенчәлекләрне бетерү, блокировкалау, юк итүгә үземнең ризалыгымны бирәм.

______________________________________
(гариза бирүченең фамилиясе, исеме, атасы исеме)

________________«____»___________ 20____ел
(имза) (дата)

Социаль файдаланудагы торак фонды
торак урыннарына наем килешүе буенча
торак урыннар тәкъдим итү турында
гражданнар гаризаларын наем бирүчеләр
тарафыннан исәпкә алу тәртибенә
2нче кушымта

Социаль файдаланудагы торак фонды торак урыннарына наем килешүе буенча торак урыннар тәкъдим итү турында гариза биргән гражданнар реестры формасы

**Социаль файдаланудагы торак фонды торак урыннарына наем килешүе буенча торак урыннар тәкъдим итү турында гариза биргән гражданнар реестры**

______________________________________________________________________

(Наем бирүченең атамасы)

| №№ пп | Гариза кабул ителгән дата | Гариза бирүче һәм гаилә әгъзалары турында мәгълүматлар | | | | Исәпкә алынган вакыт | Гариза бирүченең расписка алуы турында имзасы һәм аны алган дата | Торак урын наймы килешүен төзү турында яки гаризаны канәгатьләндерүдән баш тарту һәм баш тартуның нигезләре турында мәгълүматлар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | Гариза бирүченең һәм аның белән бергә яшәүче аның гаилә әгъзаларының фамилиясе, исеме, атасы исеме, шәхесне раслаучы документ турында мәгълүматлар | Даими яшәү урыны | Туган көн, ай һәм ел | Туганлык дәрәҗәсе | | | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | | | | | | | | |
| | | | | | | | | |

Искәрмәләр:

1. Таблицаның 1 колонкасында гариза бирүчегә реестр буенча бирелгән тәртип номеры күрсәтелә, мәсәлән «1». Әгәр гариза бирүченең гаризасында аның гаиләсе берничә кешедән торуы күрсәтелгән очракта, әлеге гариза бирүчене теркәүгә карата барлык язулар бер тәртип номеры буенча башкарыла. Шул ук вакытта гариза бирүче һәм аның белән бергә яшәүче аның гаилә әгъзалары турында мәгълүматларны тутыруга тиешле санда юллар бирелә.

2. Таблицаның 2 колонкасында гариза кергән дата күрсәтелә.

3. Әгәр гариза бирүченең гаризасында аның гаиләсе берничә кешедән торуы күрсәтелгән очракта, гариза бирүчегә һәм аның гаиләсенең һәр әгъзасына карата, конкрет гражданинга кагылышлы барлык кирәкле язулар таблицаның 3-6 колонкаларында бер дәрәҗәдә урнаштырыла.

4. Таблицаның 7 колонкасында социаль файдаланудагы торак фонды торак урыннарына наем килешүе буенча торак урыннар тәкъдим итүгә мохтаҗлар исәбенә кую турында вәкаләтле органның карары реквизитлары (дата һәм номер) күрсәтелә.

5. 7 колонкада гражданны социаль файдаланудагы торак фонды торак урыннарына наем килешүе буенча торак урыннар тәкъдим итүгә мохтаҗлар исәбенә кую вакыты күрсәтелә.

6. Таблицаның 8 колонкасында гражданин наем бирүче социаль файдаланудагы торак фонды торак урыннарына наем килешүе буенча торак урыннар тәкъдим итү турындагы гаризаны кабул итүе турында расписка алуынраслаучы, аны алган датаны күрсәтеп, имза куя. Мәсәлән, «Расписканы 2015 елның 12 июлендә алдым. (гариза бирүче имзасы)», гариза почта җибәрүе белән юнәлдергән һәм наем бирүче гаризаны кабул итү һәм исәпкә алу турында расписканы почта җибәрүе белән юллаган очракта, таблицаның 8 колонкасында языла: «Расписка почта җибәрүе белән 2015 елның 12 июлендә юнәлдерелде________________________________________(расписканы җибәргән башкаручының вазифасы)__________________________________________(фамилиясе, исеме, атасы исеме)_______(имза)».

7. Таблицаның 1-8 колонкалары наем бирүче социаль файдаланудагы торак фонды торак урыннарына наем килешүе буенча торак урыннар тәкъдим итү турында гражданнарның гаризаларын исәпкә алганда тутырыла.

8. Таблицаның 9 колонкасы наем бирүче социаль файдаланудагы торак фонды торак урыннарына наем килешүе буенча торак урыннар тәкъдим итү турында гражданнарның гаризаларын исәпкә алуны туктатканда тутырыла.

9. Таблицаның 9 колонкасында социаль файдаланудагы торак фонды торак урыннарына наем килешүе төзү турында мәгълүматлар тутырганда килешүне төзү датасы, килешүне төзү срогы, тәкъдим ителгән торак урыны мәйданы күрсәтелә. Мәсәлән, «2016 елның 17 апрелендә Мәскәү өлкәсе, Коломна шәһәре, Гагарин урамы, 74нче йорт, 21нче фатир адресы буенча 74,7 квадрат метр мәйданлы ун ел срокка социаль файдаланудагы торак фонды торак урыннарына наем килешүе төзелде».

10. Таблицаның 9 колонкасында гаризаны канәгатьләндерүдән баш тарту турында мәгълүматларны тутырганда, кире кагуның сәбәпләре күрсәтелә, мәсәлән, «2016 елның 27 апрелендә кире кагылды» һәм гариза бирүчене социаль файдаланудагы торак фонды торак урыннарына наем килешүе буенча торак урыннар тәкъдим итүгә мохтаҗ гражданнар исәбеннән, андый исәпкә алуның Россия Федерациясе Торак кодексының 91.13 статьясы 4 өлешендә нигезендә, территориясендә социаль файдаланудагы наем йортлары, наем бирүче тәкъдим иткән торак урыннар урнашкан Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органы норматив хокукый акты белән билгеләнгән тәртибе нигезендә, төшереп калдыру сәбәпләре күрсәтелә.

11. Гариза бирүчене исәпкә алу турындагы язу гамәлдән чыгарылган очракта таблицаның 9 колонкасында күрсәтелә: «Язу наем бирүченең _________ 20___елгы №______ карары нигезендә гамәлдән чыгарылды».

Социаль файдаланудагы торак фонды
торак урыннарына наем килешүе буенча
торак урыннар тәкъдим итү турында
гражданнар гаризаларын наем бирүчеләр
тарафыннан исәпкә алу тәртибенә
3нче кушымта

Социаль файдаланудагы торак фонды торак урыннарына наем килешүе буенча торак урыннар тәкъдим итү турында гариза кабул итү турында расписка формасы

**Социаль файдаланудагы торак фонды торак урыннарына наем килешүе буенча торак урыннар тәкъдим итү турында гариза кабул итү турында расписка**

Әлеге расписка белән раслана, гариза бирүче__________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасы исеме)
тәкъдим итте, ә наем бирүче__________________________________________________________
(наем бирүченең атамасы)
«___»__________ 20___елда социаль файдаланудагы торак фонды торак урыннарына наем килешүе буенча торак урыннар тәкъдим итү турында гаризаны кабул итте һәм аңа социаль файдаланудагы торак фонды торак урыннарына наем килешүе буенча торак урыннар тәкъдим итү турында гариза биргән гражданнар реестрында ______тәртип номеры бирде.

Гаризаны кабул итте ______________________________________
(вазифа)
____________________________________________________________
(гаризаны кабул итүче башкаручының фамилиясе, исеме, атасы исеме)

_________________ «____»____________20_____ел
(имза) (дата)

МП